# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Дүсмәт торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 4 «18» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында 2020 елның «18» ноябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Дүсмәт торак пунктында су башнясын коймалау һәм су скважинасына коймалар кую (материаллар сатып алу, торбаны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
-Дүсмәт торак пунктының Татарстан урамында койма тоту (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
-Дүсмәт торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
-Дүсмәт торак пунктында электр лампалары өчен махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 204 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 128 кеше, 62,7 % тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен -128 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен -0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Дүсмәт торак пунктында су башнясын коймалау һәм су скважинасына коймалар кую (материаллар сатып алу, торбаны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

-Дүсмәт торак пунктының Татарстан урамында койма тоту (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Дүсмәт торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

-Дүсмәт торак пунктында электр лампалары өчен махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Дүсмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: /О.Н.Павлов/